Мордовиядә “Һонәре буенча ин яхшы” конкурсында жинvчеләрне хормәтләделәр.
2024 елда эш урыннарында югары житештерv кvрсәткечләренә ирешкән хезмәтчәннәр Республика йортына чакырылган иде. Тантанада Мордовиянен барлык икътисад һәм социаль олкәләренен лаеклы вәкилләре арасында «Газпром газ бvлv Саранск» акционерлык жәмгыятенен йорт эчендәге газ жиһазлары хезмәтенен, Темников шәһәрендәге филиалынын газ жиһазларын эксплуатацияләv һәм ремонтлау буенча слесаре Ринат Наиль улы Урусов катнашты. Узган елнын октябрендә ул республика һонәри осталык конкурсында катнашып, II призлы урынны яулаган иде. Быел, ирешкән унышлары очен Ринат Урусов «Һонәре буенча ин яхшысы» 1 дәрәжә Дипломына лаек булды. Ринат Наиль улы Урусов vз һонәренә 12 ел багышлаган. Анын эше - газ казаннары, плитәләр, су жылыту колонкалары ботен Темников районы халкынын йортларында һәм фатирларында сәгать кебек эшләvдән гыйбарәт.
Конкурста катнашу кыен булмаган, унышнын жаваплы хезмәт елларында эшләнгән һонәри осталык белән билгеләнve турында әйтә. Үткән елгы интервьюсында болай дигән иде: “Хәер, икенче урын - беренче урын тvгел һәм ана омтылырлык нәрсәләр бар. Конкурста беренче тапкыр катнаштым”,- дип сойләгән иде Ринат Наиль улы Урусов. - Ярыш - ярыш була инде. Һәрвакыттагыча бик житди - комиссия, бернинди «шпаргалкалар» юк, тирә-юньдә видеокvзәтv. Практик биремне тиз һәм сыйфатлы башкардым. Әмма киләсе елда беренче урынны алу очен теорияне ойрәнергә кирәк”, - дигән иде. Быел нәтижәләр шатландыра – лаеклы беренче урын анарда.
Ринат Наиль улы Урусов кебекләр кон саен vзләренен эш урыннарында эшкә жаваплы монәсәбәт vрнәге кvрсәтәләр. Аларнын һонәри осталыгы тулаем филиалнын унышлы эшен дә билгели. Әйтик, 2025 ел башыннан дvрт ай эчендә «Газпром газ бvлv Саранск»нын Темников шәһәрендәге филиалы, Фәрит Набиулла улы Урусов житәкчелегендә, барлык житештерv кvрсәткечләрен vтәгән, атап әйткәндә, юридик затларга техник хезмәт кvрсәтv планнын 107,1% состав тәшкил иткән (узган елга карата vсеш темпы - 112,4%), йорт эчендәге газ жиһазларына - 105,6% (vсеш темпы - 109,3%), тозелеш-монтаж эшләре һәм технологик тоташтыру планнын 156,8% башкарылган, 11 йорт биләмәсе догазификацияләнгән (догазификацияләv кампаниясе башын-нан барлыгы 436).
Алда тагы да зур унышлар котсен, хезмәт алдынгысы!

Н.ХӘЛИЛ